РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 март, 2026 ел № 66

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезләмәсен гамәлгә ашыру максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 – 2046 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын расларга.
2. «Кукмара муниципаль районы Кукмара штп муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2014 елның 27 августындагы 19 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара поселогы башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Андреев В.Н.